РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ                                                                                    КАРАР

03.04.2026                                                                                    № 12

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
12.11.2025 №8 карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 29.12.2025 ел, №567-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 12.11.2025 ел, №8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.12 һәм 1.13 пунктлар өстәргә:

"1.12 Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль органы, шулай ук контроль чаралар уздыруга җәлеп ителә торган белгечләр, экспертлар тарафыннан рәсмиләштерелә торган документлар электрон документ рәвешендә төзелә һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

1.13. Профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль чараны үткәрү турында карарлар, контроль чараның, профилактик чараның актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контроль(күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына алар турында белешмәләр кертү юлы һәм аларга кул кую белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.»;

**1.2.**2.4 нче пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: контроль объекты контроль терләренең Бердәм реестрына белешмәләр кертелгәннән соң хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

**1.3.** 3.5.3 нче пунктта "кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «, шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша»сүзләрен естәргә.;

**1.4.** 3.6.2 пунктының 1 подпунктында. "видео-конференц-элемтә," сүзеннән соң «Инспектор «мобиль кушымтасыннан файдалану,»сүзләрен өстәргә.;

**1.5.** 4 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.11 пункты өстәргә:

«4.11. Документлар буенча тикшерелгәндә Документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан яисә «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып тапшырылырга мемкин;

**1.6.**5.12.2 пунктының икенче абзацына «карау гамәлгә ашырылырга» сүзләреннән соң «, шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып," сүзләрен өстәргә»;

**1.7.**5.6 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: "шул ук вакытта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1.1 елешендә каралган очракларда прокуратура органнары белән килештерүне таләп итми.».

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адреслары буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

**3.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов